**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«15» 04 2025 № 1229

«2025 елга Тукай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 4891 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2025 елга Татарстан Республикасы мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнарны өстәмә индексацияләү турында Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елның 7 февралендәге 5600-МР номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасында мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын финанслауның норматив принцибын гамәлгә ашыру буенча методик ярдәм күрсәтү максатында, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2025 елга Тукай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 4891 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Тукай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар» 1 кушымтада «Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативы» 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5. Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативы

| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының эш сәгатьләре саны | Азык-төлеккә чыгымнар нормативы, көнгә сум / тәрбияләнүче | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гомуми үстерү төркемнәре (шул исәптән төрле яшьтәгеләр) | | санатор төркемнәр | |
| | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән мәгариф мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән мәгариф мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3-4 | 33,88 | 42,65 | | |
| 5-6 | 81,28 | 102,39 | | |
| 7-12 | 135,49 | 170,64 | 175,78 | 234,39 |
| 24 | 169,34 | 210,66 | 219,73 | 289,36 |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 апреленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев